МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**от 19.10.2017** **№ 905 од**

Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар "Француз акционерлык җәмгыятенең" торак йортлары" ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында истәлекле урын төре буларак кертү һәм сак предметын, чикләрен һәм мәдәни мирас объекты территорияләреннән файдалану режимын раслау турында

"Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында"гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законы, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында"гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 нчы июнендә кабул ителгән "Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертү турында карар кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы 393 нче карары, 2016 нчы елның 30 нчы декабрендәге дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай нәтиҗәсе нигезендә,

**боерам**:

1. Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәниятһәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны буларак кертергә һәм мәдәни мирас объектының төрен – истәлекле урын итеп расларга.
2. Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен расларга (1 нче кушымта).

3. Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметын расларга (2 нче кушымта).

4. Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясен файдалаун режимын расларга (3 нче кушымта).


5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2017 ел_________ приказына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**картасы (схемасы)**




**Масштаб 1:1000**

**Шартлы күрсәтмәләр:**

- мәдәни мирас объекты территориясе чикләре

• 1 - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерля ноктасы

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты **территориясе чикләренең картографик тасвирламасы** түбәндәгечә үтә:

Карл Маркс урамы, 27 нче йортның агач капкасының төньяк-көнбатыш почмагыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 3,75 м ераклыкта урнашкан 1 нче ноктадан 16:49:010206:4. җир биләмәсенең төньяк чикләре буйлап көнчыгыш юнәлештә 2 нче ноктага кадәр.

2 нче ноктадан 16:49:010206:5 җир биләмәсенең төньяк чикләре буйлап көнчыгыш юнәлештә 3 нче ноктага кадәр.

3 нче ноктадан 16:49:010206:6 җир биләмәсенең төньяк чикләре буйлап көнчыгыш юнәлештә 4 нче ноктага кадәр.

4 нче ноктадан (16:49:010206:6 җир биләмәсенең төньяк-көнчыгыш почмагы) көнчыгыш юнәлештә 5 нче ноктага кадәр 4,91 м ераклыкта (16:49:010206:7 җир биләмәсенең төньяк-көнбатыш почмагы).

5 нче ноктадан 16:49:010206:7 җир биләмәсенең төньяк чиге буйлап көнчыгыш юнәлештә 7 нче ноктага кадәр.

7 нче ноктадан 16:49:010206:7 җир биләмәсенең көнчыгыш чикләре буйлап көньяк юнәлештә 8 нче ноктага кадәр.

8 нче ноктадан (16:49:010206:7 җир биләмәсенең көньяк көнчыгыш почмагы) в көнчыгыш юнәлештә 31,27 м ераклыктагы 9 ноктага кадәр (16:49:010206:8 җир биләмәсенең көньяк-көнбатыш почмагы).

9 нчы ноктадан (16:49:010206:8 җир биләмәсенең көньяк-көнбатыш почмагы) в көньяк-көнбатыш юнәлештә 17,40 м ераклыктагы 10 нчы ноктага кадәр (16:49:010206:23 җир биләмәсенең төньяк-көнчыгыш почмагы).

10 нчы ноктадан 16:49:010206:24 җир биләмәсенең төньяк чиге буйлап көнчыгыш юнәлештә 14 нче ноктага кадәр.

14 нче ноктадан көнчыгыш юнәлештә 5,29 м ераклыкта 15 нче ноктага кадәр (16:49:010206:60 җир биләмәсенең төньяк-көнбатыш почмагы).

15 нче ноктадан 16:49:010206:60 җир биләмәсенең көнбатыш чиге буйлап көньяк юнәлештә 16 нчы ноктага кадәр.

16 ноктадан (16:49:010206:60 җир биләмәсенең көньяк-көнбатыш почмагы) көньяк юнәлештә 20,80 м ераклыктагы 17нче ноктага кадәр (16:49:010206:24 җир биләмәсенең көньяк-көнчыгыш почмагы).

17 нче ноктадан (16:49:010206:24 җир биләмәсенең көньяк-көнчыгыш почмагы) көньяк юнәлештә 24,90 м ераклыктагы 18 нче ноктага кадәр (16:49:010206:27 җир биләмәсенең төньяк-көнчыгыш почмагы).

18 нче ноктадан көньяк юнәлештә 16:49:010206:27 җир биләмәсенең көнчыгыш чиге буйлап 19 нчы ноктага кадәр.

19 нчы ноктадан (16:49:010206:27 җир биләмәсенед көньяк-көнчыгыш почмагы) көньяк юнәлештә Энгельс урамының машина юлы кырые буйлап 21 нче ноктага кадәр.

21 нче ноктадан көньяк-көнбатыш юнәлештә Энгельс урамының машина юлы кырые буйлап 24 нче ноктага кадәр.

24 нче ноктадан төньяк юнәлештә агач койма ачыклыгы буйлап 27 нче ноктага кадәр.

27 нче ноктадан төньяк-көнчыгыш юнәлештә агач койма буйлап квратал эченә таба 30 нчы ноктага кадәр.

30 нчы ноктадан төньяк юнәлештә күрше җир биләмәсенең агач коймасы ачыклыгы буйлап 31 нче ноктага кадәр.

31 нче ноктадан агач койма ачыклыгы буйлап көньяк-көнбатыш, Красный переулок урамы буйлап көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш юнәлешләрдә 34 нче ноктага кадәр.

34 нче ноктадан төньяк юнәлештә Красный переулок урамы буйлап күрше җир биләмәсенең агач коймасы ачыклыгына хәтле 35 нче ноктага кадәр.

35 нче ноктадан көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш юнәлешләрдә 39 нчы ноктага кадәр.

39 нчы ноктадан төньяк юнәлештә 16:49:010206:340 җир биләмәсенең көнчыгыш чиге буйлап 42 нче ноктага кадәр.

42 нче ноктадан төньяк юнәлештә 0,40 м ераклыктагы 1 нче ноктага кадәр.

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Характерлы нокта күрсәтелеше | Координаталар* | | WGS-84 координаталар системасы | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | төньяк | көнчыгыш |
| | | | ° | ° |
| 1 | 482740,75 | 1266373,46 | 55°51'2.575" | 48°29'41.282" |
| 2 | 482736,95 | 1266402,32 | 55°51'2.460" | 48°29'42.942" |
| 3 | 482732,64 | 1266433,75 | 55°51'2.328" | 48°29'44.751" |
| 4 | 482729,24 | 1266468,00 | 55°51'2.227" | 48°29'46.721" |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | 482728,67 | 1266472,86 | 55°51'2.210" | 48°29'47.000" |
| 6 | 482727,45 | 1266489,46 | 55°51'2.174" | 48°29'47.955" |
| 7 | 482726,20 | 1266503,14 | 55°51'2.137" | 48°29'48.742" |
| 8 | 482696,10 | 1266499,41 | 55°51'1.163" | 48°29'48.541" |
| 9 | 482692,95 | 1266530,53 | 55°51'1.069" | 48°29'50.331" |
| 10 | 482675,78 | 1266527,63 | 55°51'0.513" | 48°29'50.172" |
| 11 | 482673,40 | 1266554,59 | 55°51'0.443" | 48°29'51.722" |
| 12 | 482673,30 | 1266554,70 | 55°51'0.440" | 48°29'51.729" |
| 13 | 482672,21 | 1266554,56 | 55°51'0.405" | 48°29'51.721" |
| 14 | 482672,04 | 1266556,06 | 55°51'0.400" | 48°29'51.807" |
| 15 | 482671,46 | 1266561,31 | 55°51'0.382" | 48°29'52.109" |
| 16 | 482667,29 | 1266560,84 | 55°51'0.247" | 48°29'52.084" |
| 17 | 482646,58 | 1266558,93 | 55°50'59.577" | 48°29'51.984" |
| 18 | 482621,76 | 1266556,48 | 55°50'58.774" | 48°29'51.854" |
| 19 | 482595,92 | 1266554,10 | 55°50'57.938" | 48°29'51.729" |
| 20 | 482559,27 | 1266549,91 | 55°50'56.752" | 48°29'51.504" |
| 21 | 482547,75 | 1266548,68 | 55°50'56.379" | 48°29'51.439" |
| 22 | 482554,38 | 1266482,85 | 55°50'56.577" | 48°29'47.652" |
| 23 | 482564,43 | 1266384,55 | 55°50'56.877" | 48°29'41.998" |
| 24 | 482573,80 | 1266298,03 | 55°50'57.158" | 48°29'37.021" |
| 25 | 482586,22 | 1266299,13 | 55°50'57.560" | 48°29'37.079" |
| 26 | 482595,59 | 1266299,76 | 55°50'57.863" | 48°29'37.111" |
| 27 | 482606,51 | 1266300,03 | 55°50'58.216" | 48°29'37.122" |
| 28 | 482603,82 | 1266324,77 | 55°50'58.136" | 48°29'38.545" |
| 29 | 482603,77 | 1266330,77 | 55°50'58.136" | 48°29'38.890" |
| 30 | 482600,23 | 1266358,72 | 55°50'58.028" | 48°29'40.498" |
| 31 | 482617,20 | 1266359,81 | 55°50'58.577" | 48°29'40.553" |
| 32 | 482619,74 | 1266329,69 | 55°50'58.652" | 48°29'38.820" |
| 33 | 482646,96 | 1266332,50 | 55°50'59.532" | 48°29'38.970" |
| 34 | 482643,98 | 1266362,48 | 55°50'59.444" | 48°29'40.694" |
| 35 | 482666,75 | 1266364,26 | 55°51'0.180" | 48°29'40.786" |
| 36 | 482669,83 | 1266333,94 | 55°51'0.272" | 48°29'39.042" |
| 37 | 482695,50 | 1266337,19 | 55°51'1.103" | 48°29'39.218" |
| 38 | 482692,89 | 1266366,65 | 55°51'1.026" | 48°29'40.912" |
| 39 | 482692,74 | 1266368,37 | 55°51'1.022" | 48°29'41.011" |
| 40 | 482693,84 | 1266368,49 | 55°51'1.057" | 48°29'41.017" |
| 41 | 482709,62 | 1266370,16 | 55°51'1.568" | 48°29'41.106" |
| 42 | 482740,37 | 1266373,41 | 55°51'2.563" | 48°29'41.279" |

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2017 елгы________ приказына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының
**сак предметы**

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметы булып түбәндәгеләр санала:

– Истәлекле урын урнашкан районның тарихи рельефы: характеристикалары, параметрлары (шул исәптән рельеф билгеләре) һәм элеге урын рельефының 1898-1900 еллардан сакланып калган элементлары;

– урам чатларыннан панорама күренешләре һәм тирә-юньнең 1898-1900 еллар антропоген ландшафт элементлары;

– истәлекле урынның урнашуы һәм шәһәр төзелеше характеристикалары, шәһәр төзелеше композицион-планлаштыру структурасында аның роле, тышкы күренеше, конструктив чишелеше һәм балконның сакланып калынган чын элементлары (каслин коелмалы колонна);

– истәлекле урынның урнашуы, аның тарихи сакланган чикләре;

– 1898-1900 еллардагы истәлекле урынның күләм-киңлек композициясе, шу исәптән тарихи кыйммәткә ия обьектларның габаритлары, биеклек һәм силуэт хакрактеристикалары, аларны масштаб чагыштырмасы, йортлар арасындагы ераклык, фасадлар бизәлеше – диварларны горизонталь тышлау, цоколь штукатуркасы; агач һәм штукатурланган элементларнынң буялышы;

– 1898-1900 еллардагы истәлекле урынның мәйдан-планлаштыру структурасы, шул исәптән тарихи кыйссәткә ия объектларның урнашуы, төзелешле һәм буш мәйданнарның чагыштырмасы;

– истәлекле урын чикләрендә урнашкан тарихи кыйммәткә ия объектлар:

– :

Торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 12);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 14);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 16);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 18);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 20);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 22);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 24);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Карл Маркс урамы, 27);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Карл Маркс урамы, 29);
торк йорт, 1898 - 1900 еллар. (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Карл Маркс урамы,31);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Карл Маркс урамы, 33);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 3);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 4);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 5);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 6);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 7);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 8);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар. (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 9);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 10);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 11);

торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 12);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 13);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 14);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 15);
торак йорт, 1898 - 1900 еллар (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Красный тыкрыгы, 16).

– тарихи кыйсмматкә ия объектларның архитектур характеристикалары һәм конструктив элементлары:

ике катлы турыпочмаклы бинаның күләм-киңлек композициясе (йортның төп күләменең зурлыгы 16,5х10,5 м (беренче тип йорт өчен) һәм 12,5х8,6 (икенче тип йорт өчен), йортның биеклеге түбә очына кадәр 9 м);

конструктив схема, сакланып калган кирпеч диварлар, җәясыман беркеткечләр; икенче кат һәм керү төркемнәре материалы – агач;

тарихи конфигурация, геометрия, иңүчу түбәнең конструктив чишелеше, түбә материалы – табаклы тимер;

фасадларның бизәлеше һәм архитектур детальләре: беренче кат почмакларында калаклар; чыгып тора торган замковлы ташлы, импостлы һәм киштәле тәрәз төпләре булган беренче катның киң һәм фигуралы йөзлекләре; нечкә гуртлы фриз; икенче катның уеп ясалган йөзлекле, турыпочмаклы тәрәзәләре;

– ишек һәм тәрәзә уемнары тарихи тутырылышы урнашуы, пропорцияләре, геометриясе һәм конструкциясе, тутыру материалы – агач.

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2017 елгы_________боерыгына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын
**файдалану режимы**

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

җир биләмәсен файдалану, мәдәни мирас объектын җир биләмәсен һәм капиталь төзелеш объектларын түбәндәге рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча заманча куллануга яраклаштыру (рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары Россия Федерациясе икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 нче сентябрендә кабул ителгән 540 нчы номерлы “Җир биләмәләрен фадаланунын рөхсәт ителгән төрләре классификаторын раслау турынлагы” боерыгы нигезендә күрсәтелгән):

- төзелеш мәйданы җир биләмәсенең 20 % тан артыгын тәшкил итмәгән очракта шәхми торак төзелеше (код 2.1),
- шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару өчен (код 2.2),
- капиталь төзелеш объектларын иҗтимагый файдалану (код 3.0),
- коммуналь хезмәт күрсәтү (код 3.1),
- социаль хезмәт күрсәтү (код 3.2),
- көнкүреш хезмәте (код 3.3),
- сәламәтлек саклау (код 3.4),
- белем бирү һәм мәгариф (код 3.5),
- мәдәни үсеш (код 3.6),
- дини файдалану (код 3.7),
- иҗтимагый идарә (код 3.8),
- эшкуарлык (код 4.0),
- эшлекле идарә (код 4.1),
- кибетләр (код 4.4),
- банк һәм иминият эшчәнлеге (код 4.5),
- иҗтимагый туклану (код 4.6),
- кунакханә хезмәте (код 4.7),

- тарихи-мәдәни эшчәнлек (код 9.3);
- гомуми кулланылыштагы җир биләмәләре (территорияләр) (код 12.0);
- бакчачылык (код 13.1),
- бакчачылык (код 13.2).

истәлекле урынның сак предметы булып саналган капиталь төзелеш объектларын саклау,архитектур-стилистик характеристикаларны саклап калган хәлдә капиталь ремонт үткәрү;

капиталь төзелеш объектларын түбәндәге таләпләргә туры китереп реконструкцияләү: төзелеш параметрларына (йортның төп күләме зурлыгы 16,5х10,5 м. (беренче тип йортлар өчен) һәм 12,5х8,6 м (икенче тип йортлар өчен), түбә очына кадәр йорт зурлыгы 9 м); төзелеш материалына һәм фасад бизәлешенә (беренче кат – кирпеч, икенче кат – агач, керү тамбурлары - агач); тәрәзә тутырылышлары параметрларына, материалына 1әм геометриясенә (агач Т-рәвешендәге йөзлекле беркетмәләр); түбә характерына (30 градустан да артык иңмәгән ике кыеклы түбә, конструкция материалы – агач, тышлык – түбә калае); ачык, җете төзләр куллануны искәртә торган төсләр берлегенә.

Реконструкция барышында биеклек параметрлары “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урынының расланган сак предметына кәрниз һәм түбә очы истәлекле урынның сак предметы саналган объектның кәрнизе һәм түбә очы белән бертигез булу шарты белән туры килә;

Тарихи-шәһәр төзелеше объектларын тарихи-архив ачыклауларга нигезләнеп яңадан төзеп торгызу;

Истәлекле урынның сак предметына караган тарихи кыйммәткә ия объектларын саклау һәм эшчәнлеген тәэмин итү өчен тиешле төзелеш корылмалары төзү сак предметына караган объектларның барлык характеристикаларын саклаган очракта гына мөмкин: (йортның төп күләме зурлыгы 16,5х10,5 м. (беренче тип йортлар өчен) һәм 12,5х8,6 м (икенче тип йортлар өчен), түбә очына кадәр йорт зурлыгы 9 м);

павильоннар, киосклар, кече архитектура формаларын истәлекле урынның сак предметын тәшкил иткән тарихи кыйммәткә ия объектларга стилистик яктан туры килерлек итеп, традицион материаллар файдаланып урнаштыру;

җир казу, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләрне археологик мирас объектларын саклау таләпләрен истә тотып башкару;

тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булмаган капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларын сүтү, тарату;

эшләп килә торган инженерлык инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү;

җәяү йөрү урыннарын һәм тротуарларны түшәүдә традицион материаллар яки табигый материалга охшаш башка материаллар (агач, таш, чуерташ катнашмасы) куллану, җыелган һәм яңгыр сулары агылышын оештыру;

кызыл сызык буенча биеклеге 1,8 метрдан артмаган үтә-күренмәле киртә торгызу мөмкин;

архитектур мохит элементларына туры килә тоган аерым төнге яктырту җайланмалары урнаштыру;

гомуми кулланылыштагы урыннарны яшелләндерү, булган кыйммәтле токымлы агачларны саклау һәм яңаларын утырту, чәчәк түтәлләре һәм газоннар ясау;

вандалларга каршы, архитектур мохит элементларына туры килә тоган урам җиһазлары (эскәмияләр, чүплекләр) урнаштыру;

фасадларда истәлекле урынның сак предметын тәшкил итә торган тарихи кыйммәткә ия объектлар чорына туры килерлек үрнәктә мәгълүмати конструкцияләр (алтакталар) урнаштыру;

махсус каралган мәйданчыкларда җирле нормативларга туры килерлек парковка урыннары санын исәпләгән хәлдә ачык парковкалар көйләү.

Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре, Энгельс урамы, 10 – 24 адресы буенча урнашкан 1898 – 1900 еллар “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урыны җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

“Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урынының сак предметын тәшкил иткән капиталь төзелеш объектларын үзгәртү;

Фасадлар бизәлешендә заманча бизәү материаллары куллану ( сайдинг, керамогранит һ.б.), фасадларның 30 % тан артык мәйданын пыялалау, яссы түбәләр яисә авышлыгы 30 градустан артык түбәләр ясау һәм төзелешнең биеклеге тарихи кыйммәткә ия, “Француз акционерлык җәмгыятенең” торак йортлары (Полукамушки)” истәлекле урынының сак предметын тәшкил итүче капиталь төзелеш объекты биеклегеннән артып китү;

җир өстеннән инженерлык коммуникацияләрен үткәрү;

булган һәм яңа төзелгән капиталь төзелеш объектларын җитештерү максатларында куллану (шартлау һәм янгын куркынычы булган предприятиеләр);

тарихи мирас объектларына, тарихи кыйммәткә ия төзелешкә табигый ландшафтка, рельефка зыян сала торган төзелеш технологияләре куллану;

гомуми кулланылыштагы биналар фасадына кондиционерлар, антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

җир биләмәләре чикләре буйлап ябык киртәләр урнаштыру;

тышкы реклама чаралары урнаштыру;

санитария максатларыннан тыш агачларны кисү.